ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендә “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына микрозаемнар бирүче” сүзләрен “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга микрозаемнар бирүче” сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 статьяның 3 өлешендәге 7 пунктында “13 статьясындагы 4 өлешендә” сүзләрен “13 статьясындагы 4 өлешенең 1 пунктында” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 8-ТРЗ